СОВЕТ
СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ-ТӘРБИТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«8» июнь 2020 ел Иске-Тәрбит ав. № 9

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске-Тәрбит авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы 2020 елның 1 апрелендәге 103-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы 2020 елның 22 апрелендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске-Тәрбит авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске-Тәрбит авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2019 елның 31 октябрендәге 22 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске-Тәрбит авыл җирлеге Советы карары белә расланган (2020 елның 27 февралендәге 4 номерлы үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске-Тәрбит авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

22 статьяның 2 пунктында, 27 статьяның 4 пунктында «һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга;

27 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Гарантның принципалга регресс таләбе хокукын күздә тотмаган муниципаль гарантия белән бары тик хуҗалык җәмгыяте йөкләмәләре генә тәэмин ителергә мөмкин, акцияләренең (өлешләренең) 100 проценты тиешле гавами-хокукый белемгә (гарантка), мөлкәте тиешле гавами-хокукый берәмлек

(Гарант) милкендә булган муниципаль унитар предприятиегә, ә Россия Федерациясе дәүләт гарантының принципалга карата регресс таләбе хокукын күздә тотмаган Россия Федерациясе дәүләт гарантиясе тарафыннан шулай ук дәүләт корпорациясе яисә Россия Федерациясе тарафыннан гамәлгә куелган (төзелгән) дәүләт компаниясе йөкләмәләре тәэмин ителергә мөмкин.»;

27 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Кредит (заем, шул исәптән облигация) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль Гарант бары тик муниципаль гарантта күрсәтелгән төп йөкләмә шартларын гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәртә алмаган һәм (яисә) кредит (займ, шул исәптән облигацион) акчаларыннан максатчан файдаланмаган очракта гына Гарант тарафыннан кире алынырга тиеш., Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) кредит шартнамәсе һәм кредит буенча муниципаль гарантия бирү турындагы шартнамә нигезендә кредитор тарафыннан кредит акчаларының максатчан кулланылышын контрольдә тоту гамәлгә ашырыла.»;

27 статьяның 16 пунктындагы 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

2021 елның 1 гыйнварына кадәр 10 статьяның 2 пункты, 34 статьяның 2,3 пунктларын, 48 статьяның 1 абзацын, 51 статьяның 3 пунктын гамәлдә булуын туктатып торырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске-Тәрбит авыл җирлеге рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://styaberdin-kaybici.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Иске-Тәрбит авыл җирлеге Башлыгы В.Г.Тимофеев